СОВЕТ СМАИЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СМӘЕЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
2о декабрь 2024 ел.

**КАРАР**
№ 117

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының "Смәел авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Смәел авыл җирлеге " муниципаль берәмлеге Уставын Федераль законга туры китерү максатларында «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы һәм «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Смәел авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Смәел авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

- 5 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 21 пункт өстәргә:

21) "шәхси ярдәмче хуҗалык турында" 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнар алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны хуҗалык кенәгәләрендә исәпкә алуны гамәлгә ашыру;

-19 статьяның 5 пунктындагы 2 абзацында "1-7 пунктларында" сүзләрен "1-7 һәм 9.2 пунктларында"сүзләренә алмаштырырга.;

- 31 статьяның 1 пунктында «10 "санын «7" санын алмаштырырга;

-42 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле: «12) чит ил агенты статусын алу»12 пунктчасы өстәргә;

-51 статьяның 1 пунктындагы 1 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле сигезенче абзац өстәргә: - «шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнар алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны хуҗалык кенәгәләрендә исәпкә ала.».

2.Әлеге карарны Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә, Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенә дәүләт теркәвенә җибәрергә.

3.Әлеге карарны дәүләт теркәвенә алганнан соң Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baitasi.tatarstan.ru) «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән

бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә)
4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземә алам.

Смәел авыл җирлеге башлыгы,
Смәел авыл җирлеге Советы рәисе Р.Г.Йосыпов